ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БОРДЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

# КАРАР

13 март 2026 ел № 3

2025 ел өчен Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап проекты буенча халык тыңлауларын үткәрү хакында

Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге халкының «2025 ел өчен Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап» хакында карар проекты буенча фикер алышуда катнашу хокукларын саклау максатыннан, 1998 елның 31 июлендәге 145-ФЗ санлы Россия Федерациясе Бюджет кодексына, Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлегендә халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә таянып

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «2025 ел өчен Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап» хакында Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге Советы карар проекты буенча халык тыңлауларын үткәрергә.

2. Әлеге карарны авыл җирлегендә мәгълүмати стендларда һәм Тукай муниципаль районның рәсми сайтында 2026 елның 16 мартыннан дә соңга калмыйча урнаштырырга.

3. Билгеләргә

- үткәрү срогы – 1 көн;
- үткәрү вакытын – 2026 елның 23 март 14.00 сәгатьтә;
- үткәрү урынын – Тукай районы, Борды авылы, Мэктэп урамы, 3 йорт (Борды авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы, утырышлар залы);
- фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тәкъдим итү, чыгыш хокукы белән халык тыңлауларында катнашу өчен гаризалар бирү адресын – Тукай районы, Борды авылы, Мэктэп урамы, 3 йорт (эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатька кадәр);
- чыгыш ясау хокукы белән халык тыңлауларында катнашу өчен гаризалар бирү вакыты – 2026 елның 23 мартына кадәр.

4. Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге Башкарма комитетына билгеләнгән тәртип нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда «2025 ел өчен Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап» хакында карар проекты буенча халык тыңлауларын әзерләргә һәм үткәрергә.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Борды авыл җирлеге Башлыгы Р.Н.Абдульманова